**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «О недрах»**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
26 ноября 2020 года

**Статья 1**

Внести в Закон Республики Татарстан от 25 декабря 1992 года № 1722-XII «О недрах» (в редакции Закона Республики Татарстан от 6 декабря 1999 года № 2486) (Ведомости Верховного Совета Татарстана, 1992, № 11 – 12; Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2000, № 2 (2); 2001, № 12; 2004, № 7 (I часть); 2005, № 4 (I часть); 2008, № 3; 2009, № 9 – 10; 2012, № 1, № 7 (I часть), № 12 (II часть); 2014, № 1 – 2, № 4, № 5, № 12 (II часть); 2015, № 7 (I часть); 2016, № 3; Собрание законодательства Республики Татарстан, 2016, № 44 (часть I); 2018, № 22 (часть I), № 92 (часть I); 2019, № 60 (часть I); 2020, № 51 (часть I) следующие изменения:

1) абзац восьмой статьи 6 изложить в следующей редакции:

«установление порядка добычи общераспространенных полезных ископаемых на основании утвержденного технического проекта для собственных производственных и технологических нужд пользователями недр, осуществляющими разведку и добычу полезных ископаемых или по совмещенной лицензии геологическое изучение, разведку и добычу полезных ископаемых, разработку технологий геологического изучения, разведки и добычи трудноизвлекаемых полезных ископаемых или по совмещенной лицензии разработку технологий геологического изучения, разведки и добычи трудноизвлекаемых полезных ископаемых, разведку и добычу таких полезных ископаемых, в границах предоставленных им в соответствии с федеральным законом участков недр;»;

2) в статье $35^1$:

а) часть первую после слов «по результатам» дополнить словами «конкурса или»;

б) абзац шестой части второй изложить в следующей редакции:

«геологическое изучение в целях поисков и оценки подземных вод, разведка и добыча подземных вод или геологическое изучение в целях поисков и оценки подземных вод, их разведка и добыча;»;

3) дополнить статьей $35^{1.1}$ следующего содержания:

«Статья $35^{1.1}$. **Порядок предоставления права пользования участком недр местного значения по результатам конкурса**

Для участия в конкурсе на право пользования участком недр местного значения для целей, указанных в части первой статьи $35^1$ настоящего Закона, претендент на участие в конкурсе (далее в настоящей статье – заявитель) подает в орган управления государственным фондом недр заявку по форме, утвержденной Кабинетом Министров Республики Татарстан, а также представляет следующие документы и сведения:

копии учредительных документов заявителя (если заявителем является юридическое лицо);

выписка из Единого государственного реестра юридических лиц (Единого государственного реестра индивидуальных предпринимателей);

копия свидетельства о постановке заявителя на учет в налоговом органе с указанием идентификационного номера налогоплательщика;

справка из налоговых органов о наличии или об отсутствии задолженности по уплате налогов и сборов;

копии лицензий заявителя и привлекаемых подрядчиков на виды деятельности, связанные с пользованием участками недр (при наличии);

копия бухгалтерского баланса заявителя по состоянию на последнюю отчетную дату с отметкой налогового органа о его принятии;

справки из банковских учреждений о движении денежных средств по счетам заявителя в течение месяца, предшествующего дате подачи заявки;

копии договоров займа или кредита (при наличии);

копии договоров подряда (при наличии);

справка о применяемых технологиях с их описанием и перечень технических средств, необходимых для проведения буровых и горных работ, с доказательством их принадлежности заявителю либо привлекаемому подрядчику;

копия штатного расписания заявителя либо привлекаемых подрядчиков;

копии дипломов квалифицированных специалистов, которые будут осуществлять работы;

предложение размера разового платежа за пользование недрами;

технико-экономические предложения по освоению участка недр местного значения.

Копии документов должны быть заверены в установленном порядке либо представлены с предъявлением оригиналов.

Принятие решений о проведении конкурса на право пользования участками недр местного значения, о составе и порядке работы конкурсной комиссии и определение порядка и условий проведения таких конкурсов относительно

каждого участка недр или группы участков недр осуществляются органом управления государственным фондом недр.»;

4) в статье $35^8$:

а) наименование изложить в следующей редакции:

«Статья $35^8$. **Документы, необходимые для предоставления права пользования участком недр местного значения для геологического изучения в целях поисков и оценки подземных вод, для разведки и добычи подземных вод или для геологического изучения в целях поисков и оценки подземных вод, их разведки и добычи**»;

б) в абзаце первом части первой слова «оценки подземных вод и их добычи» заменить словами «оценки подземных вод, их разведки и добычи»;

в) в абзаце первом части второй слова «для добычи подземных вод» заменить словами «для разведки и добычи подземных вод»;

5) в статье $35^9$:

а) в наименовании слова «в аукционе» заменить словами «в конкурсе или аукционе»;

б) в абзаце первом слова «в аукционе» заменить словами «в конкурсе или аукционе»;

в) в абзаце втором слово «аукциона» заменить словами «конкурса или аукциона».

**Статья 2**

Настоящий Закон вступает в силу через 10 дней после дня его официального опубликования.

Президент
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
11 декабря 2020 года
№ 85-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Җир асты байлыклары турында»**
**Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2020 елның 26 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 25 декабрендәге 1722-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (1999 елның 6 декабрендәге 2486 номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1992, № 11 – 12; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2000, № 2 (2); 2001, № 12; 2004, № 7 (I өлеш); 2005, № 4 (I өлеш); 2008, № 3; 2009, № 9 – 10; 2012, № 1, № 7 (I өлеш), № 12 (II өлеш); 2014, № 1 – 2, № 4, № 5, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 3; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 60 (I өлеш); 2020, № 51 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 статьяның сигезенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«федераль закон белән үзләренә бирелгән җир асты кишәрлекләре чикләрендә файдалы казылмаларны разведкалауны һәм чыгаруны яисә берләштерелгән лицензия буенча файдалы казылмаларны геологик өйрәнүне, разведкалауны һәм чыгаруны, авыр чыгарыла торган файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, разведкалау һәм чыгару технологияләрен эшләүне яисә берләштерелгән лицензия буенча авыр чыгарыла торган файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, разведкалау һәм чыгару технологияләрен эшләүне, шундый файдалы казылмаларны разведкалауны һәм чыгаруны гамәлгә ашыручы җир асты байлыкларыннан файдаланучылар тарафыннан үзләренең җитештерү һәм технологик ихтыяҗлары өчен гомумтаралган файдалы казылмаларны расланган техник проект нигезендә чыгару тәртибен билгеләү;»;

2) $35^1$ статьяда:

а) беренче өлештә «очраклардан тыш,» сүзләреннән соң «конкурс яисә» сүзләрен өстәргә;

б) икенче өлешнең алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«җир асты суларын эзләү һәм бәяләү максатларында геологик өйрәнү, җир асты суларын разведкалау һәм чыгару яисә җир асты суларын эзләү һәм бәяләү максатларында геологик өйрәнү, аларны разведкалау һәм чыгару;»;

3) түбәндәге эчтәлекле $35^{1.1}$ статья өстәргә:

«$35^{1.1}$ статья. **Җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын конкурс нәтиҗәләре буенча бирү тәртибе**

Әлеге Законның $35^{1}$ статьясының беренче өлешендә күрсәтелгән максатлар өчен җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукына конкурста катнашу өчен конкурста катнашуга дәгъва белдерүче (әлеге статьяда алга таба – мөрәҗәгать итүче) җир асты байлыкларының дәүләт фонды идарәсе органына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган рәвештә гариза бирә, шулай ук түбәндәге документларны һәм белешмәләрне тапшыра:

мөрәҗәгать итүченең гамәлгә кую документлары күчермәләрен (әгәр мөрәҗәгать итүче юридик зат булса);

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан (Индивидуаль эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан) өземтәне;

салым түләүченең идентификация номерын күрсәтеп, мөрәҗәгать итүченең салым органында исәпкә куелуы турында таныклыкның күчермәсен;

салымнар һәм җыемнар түләү буенча бурычы булу яисә булмау турында салым органнарыннан белешмәне;

мөрәҗәгать итүченең һәм җәлеп ителәчәк подрядчикларның җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга бәйле эшчәнлек төрләренә лицензияләре (алар булса) күчермәләрен;

соңгы хисап датасына мөрәҗәгать итүченең бухгалтерлык балансы күчермәсен, аңа кабул ителүе хакында салым органы билгесе куелган булырга тиеш;

гариза биргән датага кадәр узган ай дәвамында мөрәҗәгать итүченең счетларында акчалар йөреше турында банк учреждениеләреннән белешмәләрне;

заем яисә кредит шартнамәләренең (алар булса) күчермәләрен;

подряд шартнамәләренең (алар булса) күчермәләрен;

кулланыла торган технологияләр турында, аларны тасвирлау бәян ителгән белешмәне һәм бораулау, тау эшләрен башкару өчен кирәкле техник чараларның мөрәҗәгать итүченеке йә җәлеп ителәчәк подрядчикныкы булуы расланган исемлеген;

мөрәҗәгать итүченең йә җәлеп ителәчәк подрядчикларның штат расписаниесе күчермәсен;

эшләрне башкарачак квалификацияле белгечләрнең дипломнары күчермәләрен;

җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен бер тапкыр түләүнең тәкъдим ителә торган күләмен;

җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлеген үзләштерү буенча техник-икътисадый тәкъдимнәрне.

Документларның күчермәләре билгеләнгән тәртиптә таныкланган булырга йә оригиналларын күрсәтеп тапшырылырга тиеш.

Җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукына конкурс үткәрү турында, конкурс комиссиясенең составы һәм эш тәртибе турында карарлар кабул итү һәм җир асты байлыкларының һәр кишәрлегенә яисә җир асты байлыклары кишәрлекләре төркеменә карата мондый конкурсларны үткәрү тәртибен һәм шартларын билгеләү җир асты байлыкларының дәүләт фонды идарәсе органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.»;

4) $35^{8}$ статьяда:

а) исемне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$35^{8}$ статья. **Җир асты суларын эзләү һәм бәяләү максатларында геологик өйрәнү өчен, җир асты суларын разведкалау һәм чыгару өчен яисә җир асты суларын эзләү һәм бәяләү максатларында геологик өйрәнү, аларны разведкалау һәм чыгару өчен җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын бирү өчен кирәкле документлар**»;

б) беренче өлешнең беренче абзацында «геологик өйрәнү, аларны чыгару» сүзләрен «геологик өйрәнү, аларны разведкалау һәм чыгару» сүзләренә алмаштырырга;

в) икенче өлешнең беренче абзацында «чыгару өчен» сүзләрен «разведкалау һәм чыгару өчен» сүзләренә алмаштырырга;

5) $35^{9}$ статьяда:

а) исемдә «Аукционда» сүзен «Конкурста яисә аукционда» сүзләренә алмаштырырга;

б) беренче абзацта «Аукционда» сүзен «Конкурста яисә аукционда» сүзләренә алмаштырырга;

в) икенче абзацта «аукционның» сүзен «конкурсның яисә аукционның» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2020 ел, 11 декабрь
№ 85-ТРЗ